*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

**Өченче сан** *Әдәбият елына багышланган махсус чыгарылыш* **Ноябрь, 2015 нче ел**

## Бу санда



*Гимназия сулышы* 1

*Россиякүләм «Фоат Садриев укулары - 2015»*

*Талантлы якташларыма күңелемдә һәйкәл куям...* 2

*Сездә ничек, бездә шулай - дәресләр кызык үтә* 3

*Китап галим - телсез мөгаллим* 4

*Китап уку – иң яхшы белем алу* 5

*Могҗизалы өчлек* 6

*Укучылар һәм укытучылар иҗатына багышланган сәхифә* 7

*Буш вакытың бушка үтмәсен* 8

## 2015 НЧЕ ЕЛ - РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

*Агымдагы елда Россиядә әдәбиятка багышланган зур күләмле нинди чаралар үтә? Бу турыда беләсезме?*

*Менә алар: "Әдәби Евразия", "Россиянең әдәби картасы", "Библиотөн - 2015", "Хастаханәләрдә китаплар", "Китап белән җәй", "Бөтендөнья китаплары көне" һәм башка проектлар, "Россиянең әдәби башкаласы" конкурсы.*

## Г И М Н А З И Я С У Л Ы Ш Ы

### Батулла бездә кунакта



"Әдәбият елы" кысаларында гимназиядә язучылар белән очрашулар уздырыла. Күренекле прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла белән очрашуны гимназия укучылары түземсезлек белән көтеп алды. Язучы күргәзмә белән танышты. Укучылар түгәрәкләрдәге шөгыльләре турында сөйләделәр, өч телдә чыгарылган аудиодиск, ике телдә нәшер ителүче газеталар тәкъдим ителде. Рабит Батулла гимназия китапханәсенә үзенең тормышы, иҗаты турында китап бүләк итте. Укучылар белән очрашу барышында язучы балаларны кызыксындырган күпсанлы сорауларга җавап бирде. Батулла – бик укымышлы, зыялы шәхес. Аның биргән киңәшләре, акыллы сүзе, үткен фикерләре укучылар күңелендә озак сакланыр.

### Мөслим гимназиясе укучылары - "Илһам" Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе җиңүчеләре!




15 апрельдә "Илһам" Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау тантанасы булды. Сайлау турын уңышлы узган 85 укучы "Пирамида" мәдәни-күңел ачу үзәгендә оештырылган бүләкләү тантанасында булып кайттылар. Укучылар өчен Казан шәһәренең мәдәни-архитектура һәйкәле саналган Кремль территориясенә, Кол Шәриф мәчетенә экскурсия оештырылды. Гимназиянең 8а сыйныфы укучысы Илүзә Кашапова (укытучысы Э.В.Тимергалиева) "Илһам" Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә икенче ел рәттән катнаша. Узган ел өченче премиягә ия булса, быел "Серле кунаклар" хикәясе Илүзәгә "Проза" номинациясендә 8-9 нчы сыйныфлар арасында җиңү китерде: Илүзә Кашапова беренче премия иясе булды. 10-11 нче сыйныфлар арасында гимназиянең 10 а сыйныфы укучысы Нәзилә Сәрвәрова (укытучысы З.Н.Шәнгәрәева) "Проза" номинациясендә "Тургай тыкрыгы" хикәясе белән икенче премиягә лаек дип табылды. Җиңүчеләр Казаннан яңа иҗат дәрте, күңел күтәренкелеге белән кайттылар. Җиңүләрегез дәвамлы булсын, кызлар!

### Илһамлы каләм

Сентябрь-октябрь айларында Казан Федераль Университеты тарафыннан "Илһамлы каләм" конкурсы игълан ителгән иде. Бу конкурска укучылардан проза, публицистика, поэзия буенча иҗади эшләр кабул ителде. Гимназия укучылары **Сарварова Нәзилә** һәм **Кашапова Илүзә** үзләренең проза жанрында иҗат иткән әсәрләре белән катнашып, 2 турга уздылар һәм йомгаклау турына чакырылдылар. Казанда алар күренекле язучылар, шагыйрьләр белән очраштылар, тел һәм әдәбият галимнәреннән күп сорауларга җаваплар ишеттеләр. Укучыларның эшләре югары бәяләнде.

### Матбугат битләрендә




«Әдәбият елы» кысаларында гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Тимергалиева Эльмира Василовнаның «Казан утлары» журналында «Фән» бүлегендә «Фоат Садриевның «Таң җиле» романында борынгы әдәбияттан килгән традицияләр» исемле мәкаләсе басылды.

Язма белән http://kazanutlary.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

## II РОССИЯКҮЛӘМ ФОАТ САДРИЕВ УКУЛАРЫ - 2015





Ике ел рәттән безнең районда татар халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Фоат Садриев укулары оештырыла. Укучылар фәнни житәкчеләре – татар теле мөгаллимнәре белән берлектә төрле дәрәҗәдә эзләнү-тикшеренү эшләре башкаралар. 27 нче мартта безнең гимназиядә Татарстан Республикасы Язучылар Союзыннан, “ТАТМЕДИА” ачык акционерлык җәмгыяте филиалы “Мәгариф” журналы редакциясеннән кунаклар килде. Казан шәһәре, Яр Чаллы, Минзәлә, Түбән Кама шәһәре, Мөслим, Тукай, Әлмәт, Бөгелмә, Тукай, Азнакай, Сарман, Актаныш, Мамадыш, Чирмешән, Зәй, Арча муниципаль районнары гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназияләреннән 8-11 нче сыйныф укучылары, укытучылар катнашты. Әлбәттә, бу чараның иң мәртәбәле кунагы – Фоат ага Садриев үзе! “Талантлы якташларыма күңелемдә һәйкәл куям” проекты белән чыгыш ясап, 8-9 нчы сыйныф укучылары һәм “Фоат Садриев иҗатында Ана образы” фәнни-тикшеренү эше белән Ления Мөхәммәтова беренче дәрәҗә Дипломга ия булдылар.

## ТАЛАНТЛЫ ЯКТАШЛАРЫМА КҮҢЕЛЕМДӘ ҺӘЙКӘЛ КУЯМ...

***Мөслим төбәге - күренекле шәхесләргә, талантларга бик бай төбәк. Алар иҗаты белән таныш булу – зыялылык билгесе. Яраткан язучыларга “Хыялдагы һәйкәл” проектын тәкъдим итәбез. Проектта 8а, 9б сыйныфы укучылары катнашты.***

***Түбәндәге сораулар тәкъдим ителде:***

***Сез кайсы әдипкә һәйкәл куярга уйлыйсыз?***


***Һәйкәл кайда булырга тиеш?***

***Һәйкәл өчен нинди материал кулай булыр иде?***

***Әдипне нинди кыяфәттә итеп күзаллыйсыз?***

***Һәйкәлгә нинди сүзләр язылган булырга тиеш?***

*Газетаның һәр санында сез проект нәтиҗәләре белән танышып бара аласыз.*



Татар шигъриятенең “мәтры” саналган **Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов)** Яңа Сәет авылында туган.

Зөлфәтнең һәйкәлен мин Казан паркларының берсендә агачлар арасында – ул яраткан табигать кочагында күрергә телим. Материалына килгәндә, бронза, мәрмәр, граниттан булырга мөмкин. Биек пьедестал өстендә Зөлфәт басып тора. Гәүдәсе, нәрсәдер аңлатырга, халкына олы мәхәббәтен, әйтәсе кыйммәтле сүзләрен җиткерергә теләгәндәй, алга омтылган... Бәдрә чәчләрен азрак җил тузгыткан, киң маңгай, уйчан карашлары өметле килбәткә төбәлгән. Сул кулында китап, уң кулын факел күтәргәндәй күтәреп, утлы зәңгәр күзләре өстенә җиерчыклар чыгарып, шигырь укый... Нил Юзеевча әйтсәк, шагыйрь – яңын яшәү символы. Зөлфәт шау-шулы поэзия күгендә гөлт итеп кабынды да үз әдәбияты балкышын гәүдәләндергән якты йолдыз булып балкый. Һәйкәл халкымның татар булып яшәве символы булып күз алдыма килә. Һәйкәлнең аскы өлешенә “Кан туганым, безгә ил хакында сөйләшергә кирәк күзгә-күз” сүзләре язылган.

Зөлфәт һәйкәле янында меңләгән яшьләр. Шулчак мин алар алдында, ялкынланып әдипнең “Буын” шигырен яттан сөйлим.

***Нурислам Сәлимгәрәев***



**Шәмсия Гатуф кызы Җиһангирова (Гарипова)** Баек авылында туа.

Шәмсия Җиһангирова - җырчы шагыйрә. Аның шигырьләре табигый агышлы, җырлап тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә композиторларыбыз аның иҗатына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Укучылар күңелен яулап алган повесть һәм хикәяләр, юмористик әсәрләр авторы да бит әле ул. Шәмсия Җиһангированың радиодагы эшчәнлеге дә игътибарга лаек.

“Исәннәргә һәйкәл кирәк түгел” дисәләр дә, әлеге мәсьәләне хәл итүче булсам, әллә кайчан Шәмсия апага һәйкәл куйган булыр идем. Ир-атларга куелган һәйкәлләр күп, ә хатын-кызларга, ни өчендер, һәйкәлләрне сирәк куялар.

Шәмсия Җиһангирова һәйкәле – хатын-кыз гүзәллеге, фидакарьлеге символы булып торырга тиеш. Мөслим кызлары нинди, дисәләр, мин: “Шәмсия апаныкы кебек чем кара куе чәчле, тере күзле, тезелеп торган энҗеләрдәй ап-ак тешле, елмайганда, бит очлары чокыраеп, сине сихерли торган серле, ачык йөзле, туры сүзле, тәп-төз гәүдәле,” – дип әйтер идем. Скульптор, һәйкәлне ясаганда, һичшиксез, шул таләпләрдән чыгып эш итәргә тиеш. Беркем булдыра алмаганча итеп әнисен яратучы, зурлаучы шәфкать иясе, ихластан туган җирен сагынучы, җирсеп яшәүче миллләттәшебез, бер үк вакытта кырыс та, гадел дә, таләпчән дә була белгән зат ул Шәмсия Җиһангирова. Аның һәйкәле янында олы яшьтәге апалар да, гашыйк кызкыркын да, егет-җилкенчәкләр дә җыела. Радиодан аның сүзләренә язылган җырлар яңгырый, кемдер кушылып җырлап ала, кайсыдыр шигырь укый. Аллы-гөлле күбәләкләр һәйкәл тирәсендәге хуш исле чәчәкләрне үбәләр, иркәлиләр. Якында гына кошлар сайраганы ишетелә, кечкенә генә куен дәфтәрен чыгарып, берәү күңелендәге хисләрен ак кәгазь битенә төшерә башлый. Матур хисләр уяна, яңа җыр туа, яшь талантлар туа... Минем күңелемә җыр килә...

***Тимур Салахов***



Балалар шагыйре **Мөҗәһит Заһит улы Әхмәтҗанов** Түреш авылында туган.

Мөҗәһит - әдәби иҗатын балаларга багышлаган шагыйрьләрдән. Мөҗәһитнең балалар өчен язган шигырьләре телнең авылчан гадилеге, ихласлыгы белән аерылып тора. Аларда катлаулы сурәтләр, башваткыч вакыйгалар юк, әмма һәр шигырьдә авыл дигән гаҗәеп дөнья өчен генә хас җылылык, нәзакәтлек, кызыклы тормыш детале яки гыйбрәтле бер сабак бар.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов гарәп хәрефләрен өйрәнүчеләр өчен “Күңел нуры”, “Гарәп графикасы нигезендә элекке татар язуы” исемле уку әсбаблары, туган авылы Түреш турында тарихи очерк һәм Мөслим төбәгеннән чыккан каләм ияләре турында биографик белешмә, Мөслим районындагы фольклор ансамбльләре турында “Мөслимем җәүһәрләре”, Мөслим авылындагы мәчетләр, мәдрәсә, мәктәпләр тарихына багышланган “Кыңгыраулы мәктәп еллары” исемле һ.б. китаплар авторы булырак та укучыларга билгеле. Зариф Мәэминовның кулъязмасын гарәп язуыннан кириллицага күчереп, “Мажара” җыентыгын бастырды. Бүгенге көндә яшь курайчылар түгәрәге алып бара.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов – халык мәгарифе отличнигы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, 1995 нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Мин Мөҗәһит Әхмәтҗанов һәйкәлен үзе күп еллар җитәкләгән мәктәп каршында итеп күз алдына китерәм. Бирeдә шигырь укучылар конкурслары, төрле әдәби чаралар үткәрергә булыр иде. Ә Мөҗәһит абый, сөенеп, шул чараларны күзәтеп торыр иде. Аның янында халык уен коралллары ансамбльләре чыгыш ясар, табышмак кичәләре шаулап үтәр.

***Язилә Исмәгыйлева***

## СЕЗДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ - ДӘРЕСЛӘР КЫЗЫК ҮТӘ



**Алинә Сәхипгәрәева – гимназия Президенты:** Математика, рус телен без башка мәктәпләрдәге кебек үк өйрәнәбез, ә менә биология, химия, физика, инглиз теле, информатика сингапур ысулы белән укытыла. Миңа калса, һәр ике төр дәреснең дә көчле һәм кимчелекле яклары бар. Дәрестә без бер-беребезгә киңәшче дә, белем тикшерүче дә, укытучы да – бу классны бик берләштерә. Миңа Зөлфирә Мухаровна, Венера Гайсовна, Ләйсән Фагимовнаның дәресләре бик ошый. Структураларны урынлы кулланып, алар бездән дә чын белгечләр ясыйлар. Икенче яктан караганда, бездә аралашу культурасы үсә. Минемчә, бүгенге заманда кеше белән аралаша белү бик мөһим.

**Сафиуллин Ренат - гимназия Укучылар үзидарәсенең Сәламәтлек һәм спорт министры:** Миңа, Алинә, бер өстәлгә дүрт кеше утыру ошамый. Тактага, укытучыга карарга кирәк булганда, муеннарың каерылып бетә инде. Дәрес, үзең чыгарган кагыйдә хәтердә яхшырак саклана, аңлап каласың. Теманы сиңа үз сүзләре белән классташың аңлатканда, уку ничектер җиңелрәк бирелә.

**Зәйнәп Нассер – гимназия Укучылар үзидарәсенең Мәгариф министры:** Дәресләрдә укучылар күбрәк эшли. Ачыш ясагач, рәхәт булып китә, процесска кереп киткәнеңне сизми дә каласың. Бертуктаусыз уйларга туры килә, дәрестә үзең өчен бер минут та калмый.

**Кадырова Айзилә – гимназия Укучылар үзидарәсенең Мәдәният һәм матбугат министры:** Минемчә, син укытучы өчен "серле йомгак" булудан туктыйсың, чөнки дәрес барышында укучыга һәр яктан ачыларга мөмкинлек тудырыла.

***Укучылар үзидарәсе әгъзалары белән 9 нчы а сыйныфы укучысы Муллагалиева Алсу аралашты***

*"Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк".*

*Л.Н.Толстой*

***Физика фәне дигәч, нишләптер ир-ат укытучы күз алдына килә. "Не женская эта наука" дияр идем мин... Сезнең фикерегез ничек?***

"Не женская эта наука," - дип инде... Валентина Терешкова бу сорауга җавап эзләп тормаган ләбаса, Галәм киңлекләрен өйрәнергә космоска кадәр очкан!

***Соңгы елларда шактый күп укучы физикадан БДИ сайлый. Бу нәрсә белән бәйле дип уйлыйсыз? Әллә бу берәр шаукым гынамы? Озак дәвам итәрме?***

Чынлап та, укучылар физикага ныграк тартыла. Илгә техник белгечләр җитми, техник юнәлештәге уку йортларында бюджет урыннары күбрәк бирелә башлады. Сәбәп тә шундадыр. Җәмгыять заказы үзгәрүгә карап, БДИ фәннәре дә үзгәреш кичерәдер, дип уйлыйм.



Сәяхова Зөлфирә Мөхәр кызы - югары категорияле физика укытучысы

***Тормыш кредогыз нинди?***

Җилләр җиргә аударган саен, башны күтәреп алга атлау!

***Заман укытучысын ничек итеп күз алдына китерәсез?***

Беренче чиратта, чын укытучы ул - балаларны бөтен күңеле белән яратучы. Икенчедән, белемле һәм киң эрудицияле кеше. XXI гасыр укытучысы - ирекле, кыю белгеч, идеяләрен, көчен кызганмыйча, балаларны тормышка өйрәтүче.

### Әдәбият укытучысы - укучы күңеленә күпер салучы



Авзалова Зилә Зөфәр кызы - беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

***Бүгенге чор укучысы китап укып ләззәт аламы? Бала китап укудан тәм тапсын өчен нишләргә соң?***

Әлеге сораулар барлык укытучыларны да борчый. Проблеманы хәл итүнең иң ышанычлы юлы – даими рәвештә максатчан эш алып бару. Укучы матур әдәбияттан өлге алырга тиеш. Әдәбият баланың тәрбиясенә, әхлагына, тормышка карашларына йогынты ясый, аны үз-үзенә тәнкыйть белән карарга өйрәтә. Укучының җанын тәрбияләргә дә матур әдәбият өйрәтә. Әдәбият укытучысы, әсәрләр анализлаганда, укучы күңеленә күпер сала, фәнен яраттыра ала. Бер генә фән иясенең дә бала күңеленә юл салу өчен мондый мөмкинлеге юк. Шагыйрь Равил Фәйзуллин: "Китап укып елый алганнарның күңелендә булмый каралык", - дип яза. Матур әдәбиятка якын бала дөньяның яктылыгын бәяли, гүзәллеккә гамь белән карый, начар эшләргә сәләтле булмый.

***Чулпан Алмазовна, сез укытучы буларак беренче дәресегезне хәтерлисезме?***

Әлбәттә, хәтерлим. Мин үзем тәмамлаган Мөслим мәктәбендә эшли башладым. Иң күп укучысы булган класс иде ул, күбесе белән хәзер дә аралашып торабыз.

***Дәресегезгә барганда нинди хисләр кичердегез?***

Борчылганымны хәтерлим, шулай булса да, зур канәгатьләнү хисе кичердем. Минем бала чактагы укытучы булу хыялым тормышка ашты!

***Укытучы ия булырга тиеш 3 сыйфатны әйтегез әле.***

Белемле булу, гаделлек, кешелеклелек.

***Сезнеңчә, идеаль укучыга нинди сыйфатлар хас?***

Максаты булган, тырыш, күп белергә омтылучан.

***Укытучы хезмәтенең төп күрсәткече нәрсә?***

Минемчә, фәнне тирән белүче, белемен төрле шартларда куллана алучы тәрбияле, белемле, югары әхлакый сыйфатларга ия булган укучы – һәр укытучының горурлыгы.



Хайруллина Чулпан Алмаз кызы - югары категорияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы

***Укытучылар белән 9 нчы а сыйныфы укучысы Исмәгыйлева Язилә аралашты***

КИТАП ГАЛИМ - ТЕЛСЕЗ МӨГАЛЛИМ

## Китап ничек барлыкка килгән?



Борынгы заманнардан, язма һәм басма китаплар булганчы ук инде, кешеләр әдәби әсәрләр белән таныш булганнар. Әле укый да, яза да белмәгәндә, кешеләр үз белемнәрен хәтерләрендә саклаганнар. Халык тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр телдән-телгә күчеп сөйләнгән, шул рәвешчә, кешедән-кешегә, буыннан-буынга күчә килгән. Хикәятләр, риваятьләр, легенда, миф, дастан, бәетләрне яттан сөйләүче аерым кешеләр дә булган. Аларны бездә "хикәятче", "чичән" ("чәчән"), "бәетче", кайбер халыкларда "аяклы китап" ("человек-книга"), ә борынгы грекларда "аэд" дип йөрткәннәр. Димәк, беренче китап ролен кеше үзе башкарган. Россиядә былиналар, әкиятләр жанры шулай телдән сөйләнгән. Ә бездә, татарларда, бәетләр, дастаннар, мөнәҗәтләр, әкиятләр, телдән-телгә сөйләнеп, безнең көннәргә язма хәлендә килеп җиткәннәр.

Язу барлыкка килгәнче, кешеләр истә тотуның һәм хәбәрләшүнең төрле юлларын кулланганнар. Шуларның берсе "төенле хат" булган. Ул "кипу" дип аталган. Юан бауга төрле төстәге, төрле озынлыктагы җепләр бәйләнә, шул җепләргә төеннәр төйниләр дә бауга бәйлиләр. Җептә никадәр төен булса, шулкадәр хәбәр бар дигән сүз. Кара төен – үлем, ак төен – тынычлык, яшел төен икмәкне аңлата. Буялмаган төен санны аңлата: гади төен – унлыкны, ике төен – йөзлекне һ.б.

Төенле язуны соңрак рәсемле язу алмаштыра. Аны уку бик катлаулы була. Рәсемнәрне хәтта кеше тәненә дә ясый торган булалар. Татуировкалар шуннан калган да инде. Бизәкләр җиңү, походлар санын, көчен һ.б.ны аңлаткан. Соңрак язу барлыкка килгәндә дә әле язарга кәгазь булмый.

Бездә каен тузына тимер яки өчлы сөяк белән яза башлыйлар. Көпшә сыман итеп төрелгән беренче китаплар шулай барлыкка килә. Соңрак, аны эшкәртергә өйрәнеп, китаплар ясыйлар.

Ә менә Борынгы Римда, берничә юка тактаны шомартып, уртасына балавыз агызып, шул каткан балавызга корыч таяк белән язганнар. Такталарга ике почмактан тишек ясап, шнур белән теркәп куйганнар.

Борынгы Ассириядә "китап-плиткалар" уйлап табыла. Алар йомшак кызыл балчыктан ясала. Билгеләр ясалганнан соң, чүлмәкче аны мичтә киптерә. Шулай итеп, плитәдән ясалган китаплардан зур китапханәләр барлыкка килә.

Борынгы Мисырда кешеләр "китап-тасма"лардан файдаланганнар. Алар папирус дигән үсемлектән эшләнгән. Папирусны бөгәргә ярамый, ул тиз сынучан, шуңа күрә китапларны төргәк формасында саклаганнар.

Соңрак, кәҗә, сарык, бозау тиресеннән ясалган китаплар барлыкка килә. Бу тире "пергамент" дип атала. Безнең эрага кадәр үк Кече Азиядә язу өчен тирене Пергам шәһәрендә эшкәртә башлыйлар. Тирене хлорлы известь белән агарталар, кысага тарттыралар, як-якларын тигезләп кисәләр. Аңа кош каурые белән язалар. Андый китапларның тышлыгын тактадан ясыйлар, ул тире тарттырып тышлана. Кыйммәтле металл һәм кыйммәтле ташлар белән бизәлгән бу китаплар бик авыр булалар һәм бик кыйммәт торалар.

Кәгазь яңа эраның 105 нче елында Кытайда Цай Лунь исемле кеше тарафыннан уйлап табыла.

Дөньядагы беренче басма китап XI йөздә Кытайда басылып чыга, 1445 нче елдан башлап, бөтен Европага тарала. Россиядә беренче басма китап 1564 нче елда Иван Федоров типографиясендә басыла. Ул "Апостол" була.

***Мәгълүматларны Иванов Рафаэль туплады.***

## Китап уку һәм белем алу турында мәкальләр

*Белем бәхетле итә.*

*Белемле кеше югалмас.*

*Белемнең чиге юк.*

*Китап – тормыш көзгесе.*

*Аю беләгенә ышана,*

*Адәм белеменә ышана.*

*Белемдә - көч.*

*Күп укыган күп белер.*

*Белемлекнең чиге юк.*

*Белем тәҗрибәдән туа.*

*Белем һәр куркынычны җиңә.*

*Беләктән белем көчле.*

*Белем - нур, белмәү - хур.*

## Китап - белем чишмәсе

*Китап - белем чишмәсе.*

*Укымаган бер телле, укыган ике телле.*

*Еракtагы укып беленә, якындагы күренә.*

*Күп укыган күп белер.*

*Кояш җирне яктырта, уку кешене.*

*Бүләк зур булмас, укыган кеше хур булмас.*

*Күп яшәгән ни белер, күп укыган - шул белер.*

*Укыган ил узар, укымаган ил тузар.*

*Укыган укыр, укымаган күрә сукыр.*

*Ата гыйлеме белән галим булып булмый.*

*Галим белгәнен әйтер, ахмак җиңгәнен әйтер.*

*Галим булу җиңел, адәм булу читен.*

*Галим булсаң, галәм синеке.*

*Берни белмәгән кеше һәрвакыт боек булыр.*

*Яшьлегеңдә өйрәнмәсәң, картлыгыңда үкенерсең.*

*Өйрәнгән җирдә калмас.*

# КИТАП УКУ - ИҢ ЯХШЫ БЕЛЕМ АЛУ

## Китап турында беләсезме?

Дөньядагы иң зур китап – Мисырдагы бер гыйбадәтханә стенасына уелып язылган елъязма. Аның таш "битләре"нең киңлеге 40 метр.

Кәгазьгә басылган иң калын китап – 8048 битле Библия. Авырлыгы 500 килограммлап булган бу китап Америкада саклана.

Ә иң бәләкәй китап – Японийдә. Асао Хосимо авторлыгында чыгарылган бу китапның озынлыгы – 1,4 мм, ул 20 биттән тора.

Лондон шәһәренең "Фойлз" китап кибете басма продукциясенең күплеге белән дан тота. Китап киштәләренең озынлыгы – 48 км, кибетнең мәйданы – 7044 м².

Иң а в ы р тарихи китапларның берсе – әрмән телендә. "Муша монастыре вәгазьләре" кулъязмасы. Ул башта бер пот авырлыгында булган. 1204 елда китапны басмачылар урлап киткән. Аны кире кайтару максатыннан бөтен әрмән авыллары көмеш акча җыйган. Кулъязма Муша (Көнбатыш Әрмәнстан) шәһәрендә 7 гасырдан артык вакыт саклангаи. 1915 елда төрекләр һөҗүменнән качучы әрмәннәр халыкның бу рухи хәзинәсен үзләре белән алганнар. Урау – урау юллар үтеп, кулъязма ахыр чиктә Әрмәнстанның төп китап саклау үзәгенә – Матедаранга килеп эләгә.

1832 елда Лондонда "Инглиз геройлары җыелмасы" дигән китап 100 данәдә басыла. Аның озынлыгы - 7 метрдан артык, ә киңлеге 4 метрга якын була. Хәрефләрнең зурлыгы 15 см.дан артык. Ул дөньядагы иң авыр басма исәпләнә.


1899 елда Варшава шәһәрендә, А.С.Пушкинның тууына 100 ел тулуга багышлап, күләме 28 гә 18 мм тәшкил иткән "Евгений Онегин" поэмасы басыла. Аның һәр битенә 30 юл сыйдырылган китапчыкны медальонга урнаштырырга була. Медальон капкачының уртасына, китапчыкны укыр өчен, линза беркетелгән.

1455 елда Гутенберг тарафыннан басылган Библия – дөньяда иң кыйммәтле китап булып санала. 1926 елда аның бер данәсе 350 мең долларга сатыла.

> Китап уку кешеләрнең йөзенә — нур, күңелләренә шатлык китерер. Шул сәбәпле зиһен хезмәте белән шөгыльләнүчеләр һәрникадәр арык булсалар да, гакыллары симез вә йөзләре мәхәббәтле булырлар.
>
> *Р.Фәхреддин*

**Китап синең тормышыңда нинди урын алып тора?**

*Сорауга 8 нче сыйныф укучылары җавап бирде.*



Китап - телсез укытучы.

***(Гыйзетдинова Язилә)***

Уку - минем өчен җан тынычлыгы. Авыр вакытта китап уку мине илһамландыра.

***(Гайнетдинова Ильмира)***

Уку ул – үз максатыңа ирешеп, дөрес юлдан атлау. Укып, дөрес юлдан барсаң, үзеннең бәхетеңне табарсың, зур уңышларга ирешерсең.

***(Нуриева Ильвина)***

Китап аша хисләр яңара, күңел чишмәләре айкала.

***(Шәехов Нурлан)***

Китап – белем тупланмасы. Китап укыган кеше белемле булыр.

***(Галиев Динислам)***

Китап белән президент та, депутат та булып була.

***(Салават Камалетдинов)***

Китапсыз кеше - айсыз кук йөзе.

***(Фәрхетдинова Айгөл)***

Тәрбияле, гыйлемле китапның урыны түрдә була.

***(Ямалов Ильнар)***

Китап – язмыш ачкычы.

***(Шәйхетдинова Ләлә)***

Китап уку - тәнгә физик эш эшләү сыман.

***(Әхмәтҗанов Булат)***

Китап ул - эштә – ярдәмче, ял иткәндә - кызыклы дус, һәрвакыт юл күрсәтүче маяк. Дуслаша белүчегә – якын дус, тормышны җиңеләйтүче, аң-белем өстәүче.

***(Галимова Алсу)***

Китап – кешегә азык белән су кебек бик кирәк. Китап булмаса, заманда үсеш булмас иде.

***(Зиязова Миляуша)***

## Гимназия китапханәсенә рәхим итегез!



Гомуми фонд - 13072
Дәреслекләр - 8645
Матур әдәбият - 2679
Белешмә әдәбият - 270
Методик әдәбият - 1328
Электрон уку ярдәмлекләре - 150.

***Иң күп әдәби китап укучылар:*** Ильясова Гөлнара (11б), Нассер Зайнаб (11б), Фәтхиева Алинә (3б), Бариева Илина (3б), Солтанова Алия (4б).

***Иң актив класс*** - 3б.

***Дәреслекләрне иң яхшы тотучы класс*** - 4а.

**Китап ярминкәсендә иң актив класслар** - 1б, 1в, 3б, 4а, 4б, 5б.

Китапханәдә дүрт моноблок бар. Интернет челтәренә кереп, кирәкле мәгълүматны алырга, әдәби әсәрләрне укырга мөмкин.

**Актив кулланучы** - Латыпов Таһир (6б).

Якташ язучыларның әсәрләре белән танышу өчен даими яңартылып торучы махсус мөмкинлекләр тудырылган.

## МОГҖИЗАЛЫ ӨЧЛЕК



**Кашапова Илүзә**

**«Илһам» яшь язучылар бәйгесе җиңүчесе**

**Туган көне:** 21.09.2000
**Йолдызлык:** Кыз
**Хобби:** иҗат итү
**Яраткан шөгыле:** төрле халык биюләре өйрәнү
**Хыялы:** танылган журналист булу
**Кешеләрдә нинди сыйфатлар ошый:** туры сүзлелек, үҗәтлек





**Әһлиуллина Язилә**

**Татар теленнән республика олимпиадасы призеры**

**Туган көне:** 02.03.2000
**Йолдызлык:** Балык
**Хобби:** китап уку
**Яраткан шөгыле:** халык җырларын башкару
**Хыялы:** күренекле врач булу
**Кешеләрдә нинди сыйфатлар ошый:** гаделлек

**Сәрвәрова Нәзилә**

**«Илһам» яшь язучылар бәйгесе җиңүчесе**

**Туган көне:** 04.06.1998
**Йолдызлык:** Кыз
**Хобби:** селфи ясау
**Яраткан шөгыле:** хоккей карау
**Хыялы:** укытучы булу
**Кешеләрдә нинди сыйфатлар ошый:** намуслылык, кешелеклелек, юмартлык

### ТУРГАЙ ТЫКРЫГЫ

*(Хикәя)*

Нурдидә әби, иртәнге эшләрен тәмамлап, өйгә кергәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Өй эче кояш нурлары белән яп-якты булган. Килене эшкә киткәнче, бөтен җирне җыештырып киткәнгә, йорт балкып тора. Аллага шөкер, уңды Нурдидә әби килененнән. Аш-суга да оста, йорт-җирне дә тәртиптә тота, "әнкәй" дип өзелеп тора. Шатлык өстенә шатлык өстәп, оныгы Айгөл үсеп килә. Бик зиһенле бала булыр, ахры, дип уйлап, әби оныгына күз ташлады. Тегесе рәхәтләнеп йоклый иде әле. Нурдидә әби аны үзенең әнисенә охшата. Шундый ук кара бөдрә чәчләр, карлыгандай к а р а күзләр, елмаюлары – барысы да әнисенеке кебек. Бәхете генә була күрсен! Шуларны уйлап, Нурдидә әби алгы якка чыгып, чәй куеп җибәрде. Ипиен, шикәрен алырга дип, шкаф янына килүгә, күзләре ирексездән тәрәзәгә төште. Күршесе Камилә карчык тыкрыкта кычыткан җыеп йөри икән. Менә хикмәт! Бу хәл сәер булып тоелды аңа. Соңгы елларда тыкрыкта кеше заты бик сирәк күренә иде. Кычыткан җыючы да сирәгәйде шул. Авыл халкы шәһәрләшеп ята, мал асрамый диярлек. Элек тыкрыкларда бер кычытканны да калдырмый җыеп бетерәләр иде. Ә хәзер әнә анда үтүчеләр дә сирәк. Инешкә төшүче дә юк. Һәркемнең диярлек өенә су кергән. Керне дә машина юып, чайкап бирә. Ә бит заманасында бу тыкрык гөрләп тора иде. Иртә таңнан яшь киленнәр суга төшә. Ял итсә, кер чайкарга төшүчеләр өзелеп тормый. Кышларын каз, үрдәк өмәчеләре тезелешеп, шау-гөр килеп, инешкә юнәләләр иде. Мал суйсалар, ирләр-хатыннар эчәгe юарга төшә. Ирләр боз өстендә ап-ак булганчы эчәгеләрне таптый, хатыннар бәкедә бөртекләп юалар, берсен дә әрәм итмиләр. Уен-көлкедән су буе шаулап тора. И-и-и, күңелле дә чаклар булган икән.

Камилә әбине тыкрыкта күрү бөтенләй күңелен кузгатып җибәрде Нурдидә әбинең. Хәер, кичә үк кузгалды инде ул күңел дигәннәре. Оныгы Айгөл инде. Бөтен нәрсә белән кызыксына торган тиктормас оныгы: "Әбием, бу тыкрыкны ни өчен "Тургай тыкрыгы" диләр?" - дип, телсез калдырды. Оныгының соравы төнлә дә тынгы бирмәде әбигә. Иртәнге эшләр белән онытылып торган иде, менә тагын кылт итеп исенә төште. Яраткан бабасы, әтисе, агалары күз алдыннан үтте.

Әйе, бик көчле, тырыш иде аларның нәселләре! Гомер буе хезмәттә булдылар, тырышып дөнья көттеләр. Абзар тулы мал-туар, кош-корт булды.

Нурдидә әбинең бабасы Шәйхәттәр карт үзе дә тынгысыз иде, балаларын да шуңа өйрәтте. Эшнең төмен белә иде ул. Һәр эшне җае белән, яратып, булсынга дип эшли. Көндезге ашка кайткач, бөтен мал-туарын тыкрык аша инешкә су эчәргә алып төшә. Нурдидәне дә үзе белән ала. Шакката иде кыз бу күренешкә. Бабасы алдан бара, сыерлар, бозаулар, сарыклар, бер адым да читкә тайпылмыйча, аның артыннан ияреп төшәләр. Туйганчы су эчкәннән соң, тагын тезелешеп, абзарга үз урыннарына кайталар. Ә бабасы барганда да, кайтканда да көйле-сызгырына иде. Бу гади генә сызгыру түгел. Күңелләргә үтеп керерлек бер моң иде. Нәни Нурдидә үзе дә кабатларга тырышып карады ул чакта. Бабасының сызгыруын бөтен күрше-тирә ишетә һәм аны тургай сайравына охшата. Бабасы, сызгырына-сызгырына, мал эчертергә төшкәндә, "Әнә тургай сайрый башлады инде!"- диләр иде.

Бабасы авырый башлагач, әтисе дә малларны шул ук тыкрыктан нәкъ аныңча итеп йөртте. Хәзер менә улы Хәйдәр... Менә шуннан кушылды да калды инде бу тыкрыкка "Тургай тыкрыгы" дигән исем. Шуңа бик ярата тыкрыкны Нурдидә әби. Үткән саен, бабаларын, әтисен искә төшерә ул. Уйлап карасаң, гасырдан артык тарих икән бит. Нәни Айгөленә шуларны сөйләр ул бүген. Тыкрык язмышы аларга каласы бит...

Кадерле истәлекләрдән күңеле күтәрелеп китте карчыкның. Үз эченнән нидер көйли-көйли, коймак тугларга тотынды.

***Нәзилә Сәрвәрова, 11 нче а сыйныфы укучысы***

## УКУЧЫЛАР һӘМ УКЫТУЧЫЛАР ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ



**Таң җиледәй әкрен генә назлап,**
**Бүген җанны шигырь уятты.**

### Матурлыкка карыйм сокланып

Сызылып кына таңнар аткан чакта,
Сәер генә, бераз уйланып,
Сөенеп туялмыйча, исем китеп,
Матурлыкка карыйм сокланып.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Бәхетләләр парлап узганда.
Сөенечем ташый, бәреп тышка,
Сөйгән ярым янда булганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Дус-ишләрем тугры булганда.
Гади чәчәклрәдән илһам эзлим,
Күңелләрем нурга тулганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Якыннарым бердәм булганда.
Дөрес киңәшләрен юлдаш итәр
Әткәм-әнкәм исән булганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Җемелдәшеп бакса йолдызлар.
Ачык йөзле кешеләргә карыйм –
Бу матурлык тагын тагын кайда бар?
Матурлыкка карап сокланам мин...

***Гөлназ Мирзасалихова,***
***башлангыч класслар укытучысы***

### Әнием елмаюы

Синдәй матур елмаючы
Бу дөньяда бар микән?
Нигә әни елмаюы
Шулкадәр якын икән?

Күктә - кояш, Җирдә – әни
Елмаеп җылытучы.
Сөеп, назлап, кадерләп
Иркәләп уятучы.

### Көзгә этюд

Баш очымнан гына тезелеп
Кучмә кошлар очып бара.
Көзге кояш сагышланып,
Моңсу гына озатып кала.

Кошлар киткәч агачлар да
Сагыштан саргаялар.
Яшь түгә болытлар да,
Көннәр кыска, төннәр озаялар.

Әле генә кояш иде,
Чиләкләп койды бая.
Көзге көнне аңламассың:
Я елый, я елмая…

***Әһлиуллина Язилә,***
***10 нчы б сыйныфы укучысы***

### Ашыгам

Чәчкән кебек җиргә орлыкларны
Белем гөлен сибәсем бар,
Сабыйларның күңеленә
Өмет, шатлык бирәсем бар.

Аннан кояштай иркәләп,
Үскәнен күрәсем бар,
Ык суында чыныктырып,
Зур тормышка илтәсем бар.

Киләчәккә маяк өчен
Ышаныч бирәсем бар.
Бу тормышта сыгылмаслык
Канатлар куясым бар.
Ашыгам, вакытым тар...

***Эльмира Тимергалиева,***
***татар теле һәм әдәбияты***
***укытучысы***

### Армиягә китәсең...

Озакламый безне, абыем,
Озын юл аерачак.
Син кайтуга инде бездә
Күп яңалык булачак.

Син, абыем, бер ел буе
Илебез чиген сакларсың.
Әбиемнең син кайткачтын
Беләм рәхәт суласын.

Ныклы булып, тугрылыклы
Хезмәт ит Туган илгә.
Өмет итәм: син кайтырсың -
Нур булып туган өйгә.

***Рәмилә Сәләмова,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***



### Бүләк

*(Хикәя)*

Кышкы кич. Фирүзә әстәл янында уйга чумып утыра.

Кызым, нинди уйга баттың?

Чәең суынып бетә ич.

Әнием, абыемның туган көнәнә көчек бүләк итсәм, ничегерәк булыр икән?

Бик шәп булыр, кызым.

Тиз арада гына каян табарбыз соң аны, кызым?- диде әтисе.

Күптән түгел генә Фирүзәләрнең Пушок атлы этләре картаеп дөнья куйды. Абыйсы бу югалтуны авыр кичерде, чөнки абыйсы белән Пушок бик дуслар иде. Пушок Камилне койрыкларын болгый-болгый, шатланып каршы ала иде. Камил, кая гына барса да, этне үзеннән калдырмады. Шуңа күрә дә, көчек бүләк итеп, Фирүзә абыйсының күңелен күтәрмәкче иде. Озак эзләде кыз көчекне. Абыйсының туган көне килеп җитте, ә көчек юк.

Фирүзә һәр кичтә әтисенә маллар караша. Юеш борынлы бозауларның кетер-кетер печән ашаганнарын күзәтеп торырга, учын сузып, тәмле печән белән сыйларга ярата. Шулай бер кичне, малларны карап, эшләрен төгәлләгәч, Фирүзә бакча ягына чыкты. Ак-ак кар шәлләрен бөркәнеп утырган агачларга сокланып карап торганда, әллә каян кара йомгак тәгәрәп чыкты. Кыз куркып китте. Аның аяк астында түм-түгәрәк, кара күзле, йомшак, йонлач, кара көчек бөтерелә иде. Ул туктаусыз шыңшый, аякка сарыла, җылы эзли кебек тоелды. Фирүзә як-ягына каранды, хуҗасын эзләгәндәй итте. Тик берәү дә күренмәде. Күрәсең, көчек хуҗасыз иде. Кызның шатлыгы эченә сыймады. Көчекне кулына алып, күкрәгенә кысты. Көчек "Менә ич минем хуҗам", дигәндәй, сөенеп, кызның битләрен, кулларын ялады.

Фирүзә абыйсын зур түземсезлек белән көтте. Тизрәк абыйсына шатлыклы хәбәр җиткерәсе, көчекне бүләк итәсе килде.

Шулай итеп, Бүләк ишек алды хуҗасы булып, Фирүзәләрдә яшәп калды.

***Илүзә Кашапова,***
***9 нчы а сыйныфы укучысы***

## БУШ ВАКЫТЫҢ БУШКА ҮТМӘСЕН




**Ого! Ике сообщение килгән! Фотоларга да фикер калдырганнар! Шуларны гына кереп карыйм да өй эшләренә утырам. 2 генә минут, шуннан артыгы түгел! Хәзер... хәзер...**

Берничә ел элек *Вконтакте* иң популяр социаль челтәр иде. Аны белмәгән кеше юк. ВКда утыручы кешеләрнең саны көннәр белән түгел, ә секунд саен арта торды. Ә хәзер күпчелек *Instagram*, *WhatsApp* белән хыялланган, *YouTube* блогерлары дөньясына чумган.

Кешеләрне анда утырырга нәрсә тарта икән? Шул кешеләр арасында син дә бар, мин дә бар, безнең гимназия укытучылары да бар, хәтта президентлар да бар. Мин дә шул ятьмәдә. Нәрсә тапканмындыр инде шунда. Сез үз-үзегезгә сорау бирмисезме? Ә мин бирәм. “Ни өчен утырам? Нәрсә калган соң анда?” Чынлап та нәрсә?

Мин Интернет челтәрендә көннәр буе утыруның зыяны турында яшьтәшләремә сөйли башлагач, барысы да: “Үзең дә утырасың!” – дип, күземне дә ачырмадылар.

**Гимназия укучылары буш вакытта нинди интернет-сервислар буйлап йөриләр микән?**

***Салахов Тимур, 10 класс:*** Ют уб видеохостингында Кишиневта яшәүче блогер Роман Урсу блогына язылдым. Ул кул астындагы материаллардан йорт кирәк-яраклары ясый. Мин аннан күп нәрсәләргә өйрәндем, үзем дә сизмәстән бу эшкә кереп киттем.

**Ә синең кул эшләрең белән кайда танышып була?**

«Ваши самоделки» группасына мин үземнең кайбер эшләремне урнаштырдым.

**Тимур, үзеңнең блогер буласың киләме?**

Блогерлар үз өсләренә зур җаваплылык ала. Акча эшләү мөмкинлеге булу кызыктыра, әлбәттә, ләкин видео төшерү, монтажлауга күп вакыт китә.

**Кемнәр алар геймерлар?**

***Нуретдинов Динар, 11 класс:*** Видеоуеннар белән кызыксынучылар геймер дип атала, акча эшләүче профессиональ уенчылар прогеймер була.

**Ә син нинди блогерларга өстенлек бирәсең?**

ИванГай, ПьюДиПай.

**Элина, сине Интернет нәрсәсе белән үзенә тарта?**

***Фаттахова Элина, 8 класс:*** ВК да утырам, Ютубта видеолар карарга яратам, фотоларны Инстаграмга урнаштырам. Миңа блогерлардан Мариана, Катя Клэп ошый.



*Салахов Тимурның үзе ясаган камины.*

***Укучылар белән Алсу һәм Язилә сөйләште.***

### Әйдәгез, китап укыйк!

XXI гасыр - компьютер, телефон, планшет заманы. Ә китап уку томанда кала түгелме?! Әйе, барыбыз да хәзер шул экраннарга төбәлгәнбез, бар дөньябызны онытып, шуларга чумганбыз. Ә бит бу дөньяда күпме кызыклы һәм мавыктыргыч әйберләр бар! Мәсәлән, китап, гәҗит, журналлар уку!

Быелга кадәр татарча китап укыганым бик сирәк иде. Китапханәгә татар теле укытучыбыз мәҗбүр иткәнгә генә язылган идем, татар китабының тәмен белә башладым бугай. Гимназия китапханәсендә татарча китаплар бихисап! Хәтта татарча энциклопедия дә бар икән! Фәрит Яхин хикәяләвендәге «Пәйгамбәрләр тарихы» күңелемдә калды. Бу китапта Идрис, Нух, Һуд һәм башка пәйгамбәрләр турында язылган. Күңелем гөнаһлардан, ямьсез гамәлләрдән чистарган кебек тоелды, сафланып киткәндәй булдым. Минем кешегә яхшылык кына эшлисем, Пәйгамбәрләр сыман түземле, сабыр, саф күңелле буласым килә. Минем фикеремчә, китапның кешегә тәэсир көче зур. Китапны яратыгыз!

Сез буш вакытыгызны ничек уздырасыз? Сөйләшүгә чакырабыз! Хатларыгызны электрон почтага җибәрегез: tilsim.gimnazia@yandex.ru.

***Сабитова Айгөл,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## ЯШЕРЕЛГӘН СҮЗЛӘРНЕ ТАП (13 СҮЗ)

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | И | Я | Ч | С | М | И | Т | Җ | О | К | Р | О | Л | К |
| А | Б | М | К | А | Р | И | Я | Ч | С | Ы | Й | Ш | О | Ы |
| Р | Җ | В | Ө | К | В | П | Г | Г | Т | Ш | Ө | Г | Т | Ш |
| * | О | А | А | П | Р | С | Р | О | Л | * | К | Н | Ш | * |
| К | П | Ф | Б | Ү | З | А | У | К | Е | Б | У | А | Ә | Я |
| Ы | А | Ы | У | Э | Ә | Л | А | В | Ч | А | Н | А | З | Ң |
| З | В | С | Р | Л | Э | К | Ү | И | Ю | Б | А | Е | Х | А |
| Ы | Ы | М | А | Б | Ң | Ы | Э | Җ | М | А | Р | И | Ү | * |
| А | У | Р | Н | Д | Ю | Н | У | Е | Н | Й | Н | О | Б | Е |
| И | Н | Э | Ә | З | Х | Ү | Г | Е | А | М | И | Т | Җ | Л |
| Ч | А | Ң | Г | Ы | Ы | В | П | Р | О | Т | А | У | Б | Ю |
| Й | Ө | У | К | Е | Н | Г | Ш | Ә | З | Х | Ү | Э | Д | Л |
| Й | Җ | Т | Ш | Ә | К | А | Р | * | Б | А | Б | А | Й | К |
| Ө | И | Е | О | Л | Д | Х | Ү | Э | Ң | Ш | Б | Ю | Ң | Э |
| У | Л | Н | Г | Т | И | М | Е | Р | А | Я | К | А | С | П |

ТЫЛСЫМ+

Ноябрь, 2015 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Әхлиуллина Язилә, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Муллагалиева Алсу, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Нуретдинов Динар

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Хабибуллин Руслан, Иванов Рафаэль
**Фотограф:** Нуретдинов Динар
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗаты үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru